| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | | **КАРАР** |
|---|---|---|
| от 29.05.2015 | г. Казань | № 5-3/тэ |

***«2015 елга «ТГК-16» ААҖенең электр энергиясен җитештерүнең билгеләп куелган генерацияләү куәте 25 мегаватт һәм аннан күбрәк булган җылылык энергиясе чыганаклары тарафыннан җылылык энергиясе чыганаклары коллекторларында электр һәм җылылык энергияләрен катнаш эшләп чыгару режимында җитештерелгән җылылык энергиясенә тарифлар билгеләү турында» Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитетының 2014 елның 12 декабрендәге 5-38/тэ санлы карарына үзгәрешләр кертү хакында***

«Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190 - ФЗ санлы Федераль законга, «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәяләр хасил итү турында» 2012 елның 22 октябрендәге 1075 санлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карарына, тарифлар буенча Федераль хезмәтнең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салынучы бәяләрне (тарифларны) исәпләп чыгару буенча Методик күрсәтмәләрне раслау турында» 2013 елның 13 июнендәге 760-э санлы боерыгына һәм «2015 елга электр энергиясен җитештерүнең билгеләп куелган генерацияләү куәте 25 мегаватт һәм күбрәк булган җылылык энергиясе чыганаклары тарафыннан электр һәм җылылык энергияләрен катнаш эшләп чыгару режимында җитештерелгән җылылык энергиясенә (егәрлеккә) иң чик минималь һәм максималь дәрәҗәдәге тарифларны билгеләү турында»2014 елның 10 октябрендәге 226-э/2 санлы боерыгына,Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты турындагы нигезләмәгә туры китереп, Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «2015 елга «ТГК-16» ААҖенең электр энергиясен җитештерүнең билгеләп куелган генерацияләү куәте 25 мегаватт һәм аннан күбрәк булган җылылык энергиясе чыганаклары тарафыннан җылылык энергиясе чыганаклары коллекторларында электр һәм җылылык энергияләрен катнаш эшләп чыгару режимында җитештерелгән җылылык энергиясенә тарифлар билгеләү турында» Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитетының 2014 елның 12 декабрендәге 5-38/тэ санлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1.1 | Чыганак- «ТГК-16» ААҖе филиалы- Казан ТЭЦы-3 | Бер ставкалы тариф, сум/ Гкал | 2015 елның 1 гыйн-варыннан 2015 елның 30 июненә кадәр | 453,76 | | | 574,96 | 640,33 | 702,29 |
| | | | 2015 елның 1 июленнән 2015 елның 31 декабренә кадәр | 470,81 | | | 635,80 | 705,96 | 771,74 |

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән соң ун көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы тарифлар буенча
Дәүләт комитеты рәисе вазифаларын башкаручы А.Л.Штром